**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 17 августындагы 2882 номерлы карары**

**«Казанның яңа педагогик сыйныфы» шәһәр проектында катнашучы Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре өчен конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен гамәлгә кертә торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 30 декабрендәге 3985 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен гамәлгә кертә торган Казан шәһәре Башкарма комитетының норматив хокукый актларына карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. «Казанның яңа педагогик сыйныфы» шәһәр проектында катнашучы Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре өчен конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. «Казанның яңа педагогик сыйныфы» шәһәр проектында катнашучы Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре өчен конкурс үткәрүгә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә субсидияләр бирү буенча Казан шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтле органы итеп Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсен билгеләргә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов) мәктәп укучыларына һөнәри белем бирүне гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре өчен конкурс оештыру, үткәрү һәм аның буенча түләү чыгымнарын 2026 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең бюджет исемлегендә

каралган ассигнованиеләр чикләрендә «Мәгарифне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар, гомумшәһәр чаралары» 0260243600 максатчан статьясы, 0709 бүлеге буенча 3 000 000,0 сум күләмендә гамәлгә ашырырга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 31 июлендәге 2496 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре – “Казанның яңа педагогик сыйныфы” шәһәр проектында катнашучылар өчен конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 17 августындагы
2882 номерлы карарына
кушымта

**«Казанның яңа педагогик сыйныфы» шәһәр проектында катнашучы Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре өчен конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә «Казанның яңа педагогик сыйныфы» шәһәр проектында катнашучы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән субсидия алуга Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре өчен конкурс үткәрүнең максатларын, бурычларын һәм тәртибен, шулай ук субсидия бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Әлеге нигезләмә өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

- гомуми белем бирү учреждениесе – «Казанның яңа педагогик сыйныфы» проектында катнашучы Казан шәһәре территориясендә урнашкан муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе;

- субсидия – «Казанның яңа педагогик сыйныфы» шәһәр проектында катнашучы гомуми белем бирү учреждениеләренә бирелә торган акчалар;

- конкурс нигезендә сайлап алу, конкурс – субсидияләр алу максатыннан субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен иң яхшы шартлар булдыру критерийларыннан чыгып, субсидияләр алучыларны билгеләү өчен проектларны сайлап алу ысулы;

- конкурста катнашучы – конкурста катнашу өчен гариза тапшырган гомуми белем бирү учреждениесе;

- гариза – конкурста катнашу өчен катнашучы тарафыннан әлеге нигезләмәнең 2.7 пункты нигезендә тапшырыла торган документлар;

проект – «Казанның яңа педагогик сыйныфы» шәһәр проектында катнашучы гомуми белем бирү учреждениеләрендә заманча белем бирү мохитен формалаштыруда нәтиҗәгә ирешүгә юнәлдерелгән, үзара бәйләнгән чаралар комплексы;

- жюри – конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяләү өчен

коллегиаль орган, ул конкурста җиңүчеләрне һәм субсидияләр күләмен билгеләү функцияләрен башкара.

1.3. Конкурсны уздыруның максаты – субсидия бирелә торган нәтиҗәләргә ирешүнең иң яхшы шартларыннан чыгып, субсидия алучыны билгеләү.

1.4. Бурычлар:

- укучыларга үз мөмкинлекләрен ачу, сәламәт конкуренция күнекмәләрен үстерү өчен шартлар булдыру;

- муниципаль гомуми белем учреждениеләрендә һөнәри юнәлеш бирү эшенең уңышлы тәҗрибәсен ачыклау һәм аның белән уртаклашу;

- психологик-педагогик юнәлештәге сыйныфларда белем бирү процессын оештыру модельләрен ачыклау;

- психологик-педагогик юнәлештәге сыйныф укучыларына һөнәри юнәлеш бирү эшенең бурычын нәтиҗәле гамәлгә ашыручы белем бирү процессын оештыруның перспективалы практикаларына, технологияләренә һәм модельләренә мәгълүмати, методик һәм финанс ярдәме күрсәтү.

1.5. Субсидия алучы – конкурс нәтиҗәләре буенча җиңүче дип танылган гомуми белем учреждениесе.

1.6. Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына субсидия бирү максаты – «Казанның яңа педагогик сыйныфы» шәһәр проектында катнашучы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру.

1.7. Субсидия бирү 2026 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең бюджет исемлеге чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.8. Субсидия бирү өчен бүленгән бюджет акчаларын төп бүлүче – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе (алга таба – Вәкаләтле орган).

## II. Конкурс үткәрү тәртибе

2.1. Конкурс уздыру турында белдерү «Казан мәгариф порталы» рәсми сайтында (https://obr.kzn.ru) әлеге нигезләмәне раслаган көннән алып өч эш көне эчендә урнаштырыла. Белдерүдә түбәндәге мәҗбүри мәгълүматлар булырга тиеш:

- конкурсны оештыручы атамасы, аның урнашу урыны буенча адресы, почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры һәм конкурсны оештыру өчен җаваплы затның урнашу урыны буенча адресы;

- документларны тапшыру вакыты, урыны һәм тәртибе;

- сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кабул итә башлау һәм кабул итүне тәмамлау вакыты;

- әлеге нигезләмәнең 2.4 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр;

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар тапшыру тәртибе һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган гаризаларның формасына һәм эчтәлегенә карата таләпләр;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә конкурс уздыру турында мәгълүмат урташтырыла торган сайт атамасы;

- сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кире алу тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кире кайтару тәртибе, шул исәптән сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кире кайтару өчен нигезләрне, сайлап алуда катнашучыларның гаризаларына үзгәрешләр кертү тәртибен билгели торган тәртип;

- сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

- сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны уздыру турында хәбәрнамә нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатма бирүнең башлану һәм тәмамлану вакыты;

- сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) субсидия бирү турында килешүне имзаларга тиешле вакыт аралыгы;

- сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарткан (баш тартканнар) дип тану шартлары;

- конкурсны уздыру тәэмин итела торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта конкурс нәтиҗәләрен урнаштыру көне.

Гаризалар 2026 елның 1 августыннан 2026 елның 15 августына кадәр кабул ителә.

2.2. «Казан мәгариф порталы» рәсми сайтында (https://obr.kzn.ru) сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында Вәкаләтле орган тарафыннан белдерү урнаштыру конкурста катнашучыларның гаризалар тапшыру вакыты тәмамланганчы бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

Сайлап алу «Казан мәгариф порталы» рәсми сайтында (https://obr.kzn.ru) аны гамәлдән чыгару турында белдерү урнаштырылган көннән гамәлдән чыгарылган дип санала.

2.3. Конкурс ике номинациядә үткәрелә:

- «Педагогик драйвер» (психологик-педагогик юнәлештәге сыйныфларда укучылар өчен педагогик интенсив оештыру проекты). Бер гомуми белем бирү учреждениесе конкурста катнашу өчен бер генә проект тәкъдим итә ала;

- «Педагогик сыйныф өчен педкласс» (психологик-педагогик юнәлештәге сыйныфларда укучылар өчен, Россия Федерациясендә танылган педагогларны/спикерларны чакырып, педагогик митап форматындагы чара программасын эшләү). Программа проекты бер укучы яки бер төркем укучылар (төркемдә катнашучылар саны чикләнмәгән, әмма бер проектны тәкъдим итүче барлык укучылар бер гомуми белем бирү учреждениесендә белем алырга тиеш) тарафыннан тәкъдим ителергә мөмкин.

Катнашучылар конкурста катнашу өчен конкурста элегрәк тәкъдим ителгән программаны тәкъдим итә алмыйлар.

2.4. Конкурста катнашуга дәгъва кылучы гомуми белем бирү учреждениесе субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырыла торган ай алдыннан килә торган айның 1 нче числосына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- салымнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк;

- учреждениене үзгәртеп оештыру яки ябу буенча чараларны гамәлгә ашыруга, аварияне (гадәттән тыш хәлләрне) кисәтүгә, авария (гадәттән тыш хәлләр) килеп чыкканда аның нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен башкаруга субсидия бирү очракларыннан тыш, Казан шәһәре бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы юк;

- законлы көченә кергән суд актлары, башкарма документлар буенча, шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенә караган югары башкарма органының норматив хокукый актлары, җирле администациянең муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән башка очракларда бурычны каплауга бирелә торган субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Казан шәһәре бюджетына кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы юк.

2.5. Сайлап алу ике этапта уздырыла.

Беренче (читтән торып катнашу) этап – сайлап алуда катнашучылар тарафыннан Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең төрле тармаклар юнәлешендә һөнәри әзерлек сыйныфлары белән нәтиҗәле эшен оештыруга юнәлдерелгән проектны электрон почта аша тәкъдим итү һәм тәкъдим ителгән проектларны конкурс жюрие тарафыннан карап тикшерү.

Икенче (турыдан-туры катнашу) этап – сайлап алуда катнашучылар тарафыннан проектларны яклау.

2.6. Конкурсны үткәрү вакыты:

- беренче этап – 2026 елның 25 августыннан 2026 елның 7 сентябренә кадәр;

- икенче этап – 2026 елның 9 сентябреннән 2026 елның 25 сентябренә кадәр.

2.7. Конкурсның читтән торып катнашу этабында катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар kazanobr.info@yandex.ru электрон почтасы адресына «Конкурс профи» тамгасы белән zip яки rar форматындагы бер архивлаштырылган файл белән түбәндәге материалларны тапшыра:

- теркәү формасы – конкурста катнашу өчен гариза (1 номерлы кушымта);

- проектның мәгълүмат картасы (2 номерлы кушымта);

- конкурс проектының мультимедиалы презентациясе;

- гариза бирелгән айның беренче числосына юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә;

- учреждениенең әлеге нигезләмәнең 2.3 һәм 2.4 пунктлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документлар.

Конкурста катнашучы үз инициативасы белән эшчәнлеге турында өстәмә документлар һәм материаллар, шул исәптән элегрәк гамәлгә ашырылган проектлар һәм чаралар турында мәгълүмат тапшыра.

Конкурста катнашучы, конкурс материалларын тапшырганда, конкурста катнашучы турында мәгълүматны, конкурста катнашучы тарафыннан тапшырыла торган гариза турында, конкурста катнашучы турында конкурс белән бәйле башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык бирә.

Конкурста катнашучы гаризада китерелгән мәгълүматның дөреслеге өчен җаваплы.

2.8. Конкурста катнашучылар тарафыннан тапшырылган документлар түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- pptx яки pdf форматындагы электрон презентациядә (15 слайдтан артык түгел) гомуми белем бирү учреждениесенең атамасы, гомуми белем бирү учреждениесенең тулы адресы (юридик адрестан аермалы булган очракта, юридик һәм факттагы адрес), гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе турында белешмәләр белән мәгълүмати заставка булырга тиеш. Презентациядә конвертерлар белән кысылмаган югары сыйфатлы фотосурәтләр куллану зарур, дәвамлылыгы 60 секундка кадәр булган бер генә видео файдаланырга мөмкин;

- конкурс документациясенә кертелә торган документларның (сканерлау юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларның) электрон күчермәләре документны тулысынча яисә аның фрагментын мәгълүматны карауның һәркем файдалана алырлык программа тәэминаты чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга һәм аларның эчтәлеге белән махсус программа яисә технологик чаралардан башка танышырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яки сакланган булырга тиеш түгел.

2.9. Гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документлар фактта килеп ирешкән көнне теркәлә. Гариза һәм документлар ял яки бәйрәм көнендә керсә, аларны теркәү якындагы киләсе эш көнендә гамәлгә ашырыла. Гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң Вәкаләтле органга килеп ирешкән гариза теркәлми һәм конкурста катнашуга кертелми.

2.10. Вәкаләтле орган гаризаларның әлеге нигезләмә белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен гаризалар кабул итү тәмамланган көннән алып 10 эш көне эчендә карап тикшерә.

2.11. Вәкаләтле орган түбәндәге очракларда гаризаны кире кагу турында карар кабул итә:

- сайлап алуда катнашучы әлеге нигезләмәнең 2.3, 2.4 пунктлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килми;

- сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган документлар әлеге нигезләмәнең 2.8, 2.9 пунктлары белән документларга карата билгеләнгән таләпләргә туры килми яки кирәкле документлар тапшырылмаган (тулы күләмдә тапшырылмаган);

- конкурста катнашучы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүмат дөрес түгел.

2.12. Тикшерү нәтиҗәләре буенча гаризалары 2.3, 2.4, 2.8, 2.9 пунктлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килми дип танылган конкурста катнашучыларга гаризаны кире кагу турында карар кабул ителү турында Вәкаләтле орган тикшерү тәмамланган көннән алып биш эш көне эчендә электрон почта аша хәбәр итә.

2.13. Тикшерү нәтиҗәләре буенча 2.3, 2.4, 2.8, 2.9 пунктлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килә дип танылган гаризалар тикшерү тәмамланган көннән алып өч эш көне эчендә Вәкаләтле орган тарафыннан жюри әгъзаларына тапшырыла. Вәкаләтле орган сайлап алуда катнашучыларга гаризаны жюрига тапшыру турында тикшерү тәмамланган көннән башлап биш эш көне эчендә хәбәр итә.

## III. Конкурс жюрие

3.1. Конкурс жюриеның (алга таба – жюри) шәхси составы Вәкаләтле орган әмере беләнраслана һәм «Казан мәгариф порталы» (https://obr.kzn.ru) рәсми сайтында бастырып чыгарыла.

Жюри рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән, жюри әгъзаларыннан тора. Жюри составына кимендә 7 кеше керә.

Утырышларда карарлар жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта, жюри утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала.

Жюри рәисе жюри эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, аның карарынраслый. Жюри рәисе булмаганда, аның функцияләрен жюри рәисе урынбасары башкара.

Жюри сәркатибе жюри рәисе йөкләмәсе буенча жюри утырышын әзерләүне оештыру функциясен башкара.

3.2. Жюри әгъзасының җиңүчене билгеләгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яисә турыдан-туры булмаган шәхси кызыксынуы барлыкка килгән очракта, ул, конкурс гаризаларын карап тикшерү башланганчы, бу хакта жюри рәисенә хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта әлеге жюри әгъзасы жюри эшендә катнашмый.

3.3. Жюри:

- конкурста катнашу өчен кабул ителгән документларны карап тикшерә;
- гаризаларны әлеге нигезләмә белән билгеләнгән критерийлар нигезендә бәяли;
- конкурста җиңүчеләрне билгели.

3.4. Конкурс номинацияләрендә җиңүчеләрне ачыклаганда баллар саны тигез булган очракта, жюри рәисе тарафыннан куелган бәяләр хәлиткеч булып санала.

3.5. Жюри карары катгый һәм үзгәртелми.

## IV. Гаризаларны бәяләү һәм конкурста җиңүчеләрне билгеләү тәртибе

4.1. Сайлап алуның беренче этабында проектларны сайлап алу критерийлары:

- проектның эчтәлеге;
- эш системасының бөтенлеге;
- проект чишелешенең яңалыгы һәм оригинальлеге;

- проектның гамәли юнәлеше;

- проектны башка мәктәпләрдә тиражлау мөмкинлеге;

- оештыру культурасы.

Барлык номинацияләрдә һәр критерий өч баллы шкала буенча бәяләнә, биредә: 3 – критерий тулы күләмдә чагылдырылган, 2 – критерий өлешчә чагылдырылган, 1 – критерий аз чагылдырылган, 0 – критерий чагылдырылмаган.

4.2. Турыдан-туры катнашу этабында барлык конкурсантлар да катнаша ала.

4.3. Турыдан-туры катнашу этабы кысаларында конкурсантлар үз проектларын яклап чыгыш ясыйлар.

Проектны гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе тәкъдим итә. Проектны яклауда гомуми белем бирү учреждениесе коллективының башка әгъзаларына да катнашырга рөхсәт ителә.

Чыгыш ясау регламенты – 10 минутка кадәр, жюри әгъзалары сорауларына җавап бирү – 5 минуттан артык түгел.

4.4. Бәяләү критерийлары:

- проектның актуальлеге һәм кирәклеге;

- идеянең оригинальлеге;

- фикерләүләрнең тирәнлеге һәм стандарт булмавы;

- тәкъдимнәрнең нигезләнгән булуы һәм конструктивлыгы;

- кыйммәт ориентирлары һәм шәхси позиция булу;

- презентацияләү һәм аралашу культурасы;

- педагогик бурычларны хәл итүгә иҗади якын килү;

- гомуми белем бирү оешмалары практикасында кабатлау мөмкинлеге;

- презентация материалларының сыйфаты;

- сорауларга җавап бирү сыйфаты.

Барлык номинацияләрдә һәр критерий өч баллы шкала буенча бәяләнә, биредә: 3 – критерий тулы күләмдә чагылдырылган, 2 – критерий өлешчә чагылдырылган, 1 – критерий аз чагылдырылган, 0 – критерий чагылдырылмаган.

4.5. Жюри утырышыннан соң өч эш көне эчендә жюри сәркатибе тарафыннан жюри әгъзалары куйган баллар суммасы буенча проектлар рейтингы төзелә.

4.6. Һәр номинациядә турыдан-туры һәм читтән торып катнашу этапларының барлык бәяләү критерийлары күрсәткечләрен кушу нәтиҗәсендә иң күп балл җыйган катнашучы җиңүче дип таныла. Турыдан-туры катнашу

этабында катнашкан башка проект авторлары конкурста катнашучылар дип танылa.

4.7. Субсидия Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләре арасында түбәндәгечә бүленә:

- «Педагогик драйвер» номинациясендә 5 җиңүченең һәркайсына – 450 мең сум;

- «Педагогик сыйныф өчен педкласс» номинациясендә 5 җиңүченең һәркайсына – 100 мең сум.

4.8. Конкурска йомгак ясау беркетмәсе жюри әгъзалары тарафыннан имзалана, жюри рәисе яки аның урынбасары тарафыннан раслана. Конкурста җиңүчеләр исемлеге һәм субсидия күләмнәре белән беркетмәне Вәкаләтле орган жюри сәркатибе тарафыннан гаризалар рейтингы төзелгән көннән алып өч эш көне эчендә 4.5 пункт нигезендә «Казан мәгариф порталы» рәсми сайтында (https://obr.kzn.ru) урнаштыра.

Беркетмәдә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

- гаризаларны карап тикшерү көне, вакыты һәм урыны;

- конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяләү көне, вакыты һәм урыны;

- гаризалары карап тикшерелгән конкурста катнашучылар турында мәгълүмат;

- гаризаларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризаларның конкурс уздыру турында белдерүнең кайсы нигезләмәләренә туры килмәвен күрсәтеп, гаризалары кире кагылган конкурста катнашучылар турында мәгълүмат;

- конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяләү эзлеклелеге; гаризаларны бәяләү өчен каралган һәр критерий буенча гаризаларга бирелгән күрсәткечләр; гаризаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә мондый гаризаларга тәртип номерлары бирү турында кабул ителгән карар;

- килешүләр төзелә торган субсидия алучылар атамалары һәм аларга бирелә торган субсидияләр күләме.

4.9. Конкурсның һәр номинациясендә җиңү яулаган проектларның тасвирламалары «Казан мәгариф порталы» рәсми сайтында (https://obr.kzn.ru) конкурсның электрон җыентыгында басылып чыгарга тиеш.

4.10. Конкурста җиңүчеләр проектның тасвирламасын (3 номерлы кушымта), шулай ук материалны «Казан мәгариф порталы» рәсми сайтында (https://obr.kzn.ru) конкурсның электрон җыентыгында урнаштыруга авторның рөхсәтен (4 номерлы кушымта) конкурс нәтиҗәләре игълан ителгәннән соң, өч

календарь көннән дә соңга калмыйча, info@kazanobr.ru электрон адресына юлларга тиеш.

## V. Субсидияне бирү, аңардан файдалануны контрольдә тоту, хисаплар бирү, субсидияне алучылар тарафыннан кире кайтару тәртибе һәм хисапка таләпләр

5.1. Конкурста җиңүчеләр исемлеген раслый торган жюри беркетмәсе Вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында Казан шәһәре Башкарма комитеты Финанс идарәсенең 2020 елның 29 декабрендәге 85 номерлы «Казан шәһәре бюджетыннан Казан шәһәренең муниципаль бюджет яки автоном учреждениесенә башка максатларга субсидия бирү турында килешүнең үрнәк формасын раслау хакында»гы әмере белән расланган форма буенча субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү өчен нигез булып тора.

5.2. Килешү төзү өчен конкурста җиңүче дип танылган гомуми белем бирү учреждениесе, конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат «Казан мәгариф порталы» рәсми сайтында (https://obr.kzn.ru) урнаштырылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә po.guo@mail.ru электрон почтасы адресына әлеге нигезләмәнең 5 номерлы кушымтасында китерелгән форма буенча, исемлек нигезендә тапшырылган документларның исемлеген теркәп, электрон формада гариза тапшыра. Документлар исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- субсидия суммасын исәпләү-нигезләүне, шул исәптән тиешле эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә), чаралар үткәрүгә, педагогларның квалификациясен күтәрүгә, милек (күчемсез милектән кала) сатып алуга башлангыч сметаны кертеп, бюджет акчаларын әлеге нигезләмәнең 1.6 пункты белән билгеләнгән максатларга бирү кирәклеген нигезләүне, шулай ук тәэмин итүчеләрнең (подрядчыларның, башкаручыларның) тәкъдимнәрен, статистик мәгълүматларны һәм (яки) башка мәгълүматны үз эченә алган аңлатма язуы;

- субсидия бирү максаты ремонт ясау булган очракта, ремонт ясалырга тиешле объектлар исемлеге, мондый объектларны тикшерү акты һәм дефектлар исемлеге, чыгымнарның беренчел сметасы;

- субсидия бирү максаты чаралар, шул исәптән конференцияләр, симпозиумнар, күргәзмәләр үткәрү булган очракта, чаралар программасы;

- субсидия бирү максаты күрсәтелгән түләүләрне башкару булган очракта, түләүләр алучы физик затларның саны (уртача еллык саны) һәм мондый түләүләрнең төрләре турында мәгълүмат;

- субсидия бирү максатына бәйле рәвештә башка мәгълүмат.

5.3. Вәкаләтле орган:

а) гаризаны килеп ирешкән көнне терки;

б) әлеге нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән документларның тулылыгын, алардагы мәгълүматның җитәрлек булуын һәм дөреслеген карап тикшерә;

в) гаризаны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә субсидия бирү турында килешүне имзалау хакында яки субсидия бирү турында килешүне имзалауны кире кагу хакында карар кабул итә.

Кирәкле барлык документларны тапшырмаган яки аларны тиешенчә тутырмаган очракта, Вәкаләтле орган карап тикшерү вакыты тәмамланырга кимендә ике эш көне кала әлеге документларны ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү өчен кире кайтара.

Хәбәрнамә учреждениегә Вәкаләтле органга электрон документ рәвешендә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яки Вәкаләтле органга язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан җитешсезлекләрне бетерү вакыты – әлеге хәбәрнамә гомуми белем бирү учреждениесендә теркәлгәннән соң биш эш көненнән артык түгел.

Гомуми белем бирү учреждениесе документларның тулы җыелмасын тапшырган очракта, тапшырылган документлар әлеге нигезләмәнең 1.6 пункты белән билгеләнгән максатларга туры килсә, шулай ук максатчан субсидия бирүне кире кагу өчен әлеге нигезләмәнең 5.4 пункты белән каралган нигезләр булмаса, Вәкаләтле орган биш эш көне эчендә учреждениегә субсидия бирү мөмкинлеге турында бәяләмә рәвешендә максатчан субсидия бирү турында карар кабул итә.

5.4. Субсидия алучы белән килешүне имзалауны кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез була:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге нигезләмәнең 5.2 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмау факты ачыклану;

- агымдагы финанс елында максатчан субсидияләр бирүгә структур бүлекчәнең бюджет исемлегендә каралган бюджет йөкләмәләре лимитларының тулысынча бүленүе.

Субсидия бирү турында килешүне имзалауны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта гомуми белем бирү учреждениесенә мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә, субсидия бирүне кире кагу сәбәбен күрсәтеп, бу хакта хәбәрнамә җибәрелә.

Субсидия бирү турында килешүне имзалауны кире кагу хакында хәбәрнамә гомуми белем бирү учреждениесенә структур бүлекчәгә электрон документ рәвешендә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яки структур бүлекчәгә язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Килешүне имзалауны кире кагу өчен нигез булып торган җитешсезлекләр бетерелгән очракта, гомуми белем бирү учреждениесе документларны кабат җибәрергә хокуклы.

5.5. Конкурста җиңүче Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе тарафыннан имзаланган килешүнең ике нөсхәсен алган көннән соң килә торган өч эш көне эчендә аларны имзалый һәм килешүне имзалау турында Вәкаләтле органга электрон почта адресы буенча хәбәр итә.

Конкурста җиңүче килешүне имзалау турында хәбәрнамә җибәрелгән көннән алып өч эш көне эчендә килешүнең имзаланган нөсхәсен Вәкаләтле органга шәхсән үзе тапшыра.

5.6. Килешү ике як тарафыннан имзаланганнан соң төзелгән дип санала.

5.7. Субсидия алучы тарафыннан имзаланган килешү әлеге нигезләмәнең 5.5 пункты белән билгеләнгән вакыт эчендә тапшырылмаган очракта, субсидия алучы килешү төзүдән баш тарткан дип санала һәм субсидия алу хокукыннан мәхрүм ителә.

5.8. Килешүдә субсидия бирүнең максатлары; субсидия бирүнең конкрет, үлчәнелә торган нәтиҗәләре күрсәткечләре; тиешле программалар, проектлар нәтиҗәләренә ирешү барышында алырга планлаштырыла торган матди һәм матди булмаган объектлар һәм (яисә) хезмәтләр өлешендәге күрсәткечләрне дә кертеп (мондый детальләштерү мөмкинлеге булганда), субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр; субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы; субсидия күләме; субсидия күчерү сроклары (графигы); хисап бирү сроклары; учреждение килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм сроклары; бюджет акчаларын алучы буларак, гамәлгә куючы органга субсидия бирүгә элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары киметелгән очракны да исәпкә алып, килешүгә

үзгәрешләр кертү тәртибе һәм моның өчен нигезләр; учреждениене үзгәртеп оештыру (кушылу рәвешендәге үзгәртеп оештырудан тыш) яки бетерү, учреждение тарафыннан хокукый актта һәм (яисә) килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозу, килешүне учреждение тарафыннан берьяклы тәртиптә өзүне тыю белән бәйле очракларны да исәпкә алып, гамәлгә куючы орган карары буенча килешүне берьяклы тәртиптә вакытыннан алда туктату өчен нигезләр күрсәтелә.

Килешү проектын формалаштыру, максатчан субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары булганда, Вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.9. Максатчан субсидия психологик-педагогик юнәлештә белем алучылар өчен педагогик интенсив уздыру чыгымнарын бер тапкыр финанслауга, шул исәптән түбәндәгеләр өчен бирелә:

а) кулланма материаллар һәм инвентарь белән тәэмин итү;

б) матди-техник яктан тәэмин итү;

в) оештыру һәм үткәрү хезмәтләре өчен түләү.

5.10. Психологик-педагогик юнәлештәге сыйныфларда белем алучылар өчен педагогик интенсивны әзерләү, оештыру һәм уздыру, шул исәптән кулланма материаллар һәм инвентарь сатып алу, матди-техник яктан тәэмин итү, оештыру һәм үткәрү хезмәтләре өчен түләү субсидия бирү нәтиҗәсе булып тора.

5.11. Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткеч – психологик-педагогик юнәлештәге сыйныфларда белем алучылар өчен кимендә бер тапкыр педагогик интенсив уздыру.

5.12. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе субсидияне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының территориаль бүлкчәсендә субсидия алучы тарафыннан ачылган исәп-хисап счетына килешү төзелгән көннән алып 10 эш көне эчендә күчерә.

5.13. Субсидия алучы, хисап елыннан соң килә торган елның 10 гыйнварыннан да соңга калмыйча, килешү белән каралган форма нигезендә һәм срокларда Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

5.14. Вәкаләтле орган килешү белән каралган хисаплар нигезендә һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2024 елның 27 апрелендәге 53н номерлы әмере белән расланган Тәртипкә ярашлы рәвештә субсидия бирү нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткеченә ирешү өчен билгеләнгән бөтен чор

дәвамында субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешүгә һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараның тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларга мониторинг уздыра.

5.15. Хисап бирелә торган финанс елында файдаланылмаган максатчан субсидияләрнең калган өлешләре Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелергә тиеш.

5.16. Хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе Казан шәһәре Башкарма комитетынең Финанс идарәсенә, килешүдә билгеләнгән вакытларда кабул ителгән чыгым йөкләмәләре булмау сәбәпле, максатчан субсидия акчаларының хисап елы булган финанс елында файдаланылмаган һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кайтарылырга тиешле калган өлеше турында мәгълүмат җибәрә.

5.17. Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан субсидияләр булган гомуми белем бирү учреждениеләре тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән керемнәрне максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларга ирешү өчен агымдагы финанс елында файдалану турындагы карар, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе белән килештереп, учреждение тарафыннан кабул ителә.

Максатчан субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган, учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән акчалардан агымдагы финанс елында файдалану турында карар кабул итү өчен учреждениеләр Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә учреждениенең учреждениеләр тарафыннан агымдагы финанс елының 1 гыйнварына элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан алынган акча финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган үтәлмәгән йөкләмәләре булуы турында мәгълүматны, шулай ук учреждениенең әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуын һәм күләмен раслый торган документларны (документларның күчермәләрен), акча килеп ирешкәннән соң, өч эш көне эчендә тапшыра.

Вәкаләтле орган, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат килеп ирешкәннән соң, 10 эш көне эчендә килештерү/килештермәү турында карар кабул итә.

5.18. Россия Федерациясе законнары нигезендә Вәкаләтле орган субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, үтәлешен тикшерә.

Муниципаль финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет

кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрәләр.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен бәяләү мөмкин булмаган очракта, урынга чыгып тикшерү үткәрелә. Субсидия алучы контроль өчен керү мөмкинлеген тәэмин итәргә, шулай ук күчмә тикшерү барышында субсидия бирү белән бәйле соралган документларны тапшырырга тиеш.

5.19. Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча учреждениенең максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәве ачыкланган очракта, максатчан субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәсә, шулай ук учреждение әлеге нигезләмәнең V бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә максатчан субсидиядән файдалану турында хисаплар тапшырмаса, максатчан субсидия Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

5.20. Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда, шул исәптән шартларның үтәлмәве Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерү фактлары буенча ачыкланган очракта, бирелгән субсидия Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән башлап 30 эш көне эчендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

5.21. Акчаларны Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты керемենә үз теләге белән кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә 30 көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

5.22. Субсидия акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалану өчен, шулай ук субсидия алу максатыннан тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә субсидия алучы учреждение җитәкчесенә йөкләнә.

«Казанның яңа педагогик сыйныфы»
шәһәр проектында катнашучы
Казан шәһәренең муниципаль
гомуми белем бирү учреждениеләре
өчен конкурс үткәрү тәртибе турында
нигезләмәгә 1 номерлы кушымта
(Форма)

**Мәктәп укучыларына һөнәри белем бирүне гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре өчен конкурсның ________________________________ номинациясендә катнашуга**

________________________________________________________________
(гомуми белем бирү учреждениесе атамасы)

**теркәү формасы**

| Гомуми белем бирү учреждениесенең тулы атамасы (кыскартуларсыз) | Гомуми белем бирү учреждениесенең почта адресы | Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенең телефон номеры, электрон почта адресы |
|---|---|---|---|
| | | | |

«Казанның яңа педагогик сыйныфы»
шәһәр проектында катнашучы
Казан шәһәренең муниципаль
гомуми белем бирү учреждениеләре
өчен конкурс үткәрү тәртибе турында
нигезләмәгә 2 номерлы кушымта
(Форма)

**Проектның _________________ номинациясендә мәгълүмат картасы**

| | |
|---|---|
| Гомуми белем бирү учреждениесе атамасы | |
| Проект темасы | |
| Проектның максаты | |
| Проектның бурычлары | |
| Проект бурычлары юнәлдерелгән максатчан аудитория | |
| Проект чишелешләренең яңалыгы, оригинальлеге, бөтенлеге | |
| Проектны гамәлгә ашыру этаплары | |
| Проектны гамәлгә ашыру вакыты | |
| Проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле ресурслар | |
| Проектны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр | |
| Проектны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган куркынычлар | |
| Проектны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган куркынычларны киметү чаралары | |

«Казанның яңа педагогик сыйныфы»
шәһәр проектында катнашучы
Казан шәһәренең муниципаль
гомуми белем бирү учреждениеләре
өчен конкурс үткәрү тәртибе турында
нигезләмәгә 3 номерлы кушымта

**Бастырып чыгару өчен материалны рәсмиләштерүгә таләпләр**

Бастырып чыгару өчен җибәрелә торган материал проект тасвирламасыннан гыйбарәт булырга тиеш.

Проект тасвирламасының электрон варианты doc форматында Microsoft Word текст мөхәррирендә башкарыла.

Текстның компьютерда җыелган варианты түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш: форматы – А4; кырлары – барлык яктан 2 см; гарнитура (шрифт) – Times New Roman; кегль – 14; сүзләр юлдан-юлга күчерелми, юлара интервал – 1,0; абзац чигенеше (кызыл юл) – 1,25 см.

Бастырып чыгару өчен материалның максималь күләме – 5 биттән артык түгел.

Исеме баш хәрефләр, калын шрифт белән язылa, юл үзәге буенча тигезләнә. Исем астында авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме (кыскартуларсыз) калын курсив шрифт белән күрсәтелә, вазифасы, эш урыны киләсе юлда курсив шрифт белән бирелә. Автор турындагы мәгълүматлар уң як буенча тигезләнә. Авторлар берничә булса, һәр автор өчен мәгълүмат кабатлана.

Әдәбият исемлеге алфавит тәртибендә бирелә, ГОСТ Р 7.0.5 – 2008 нигезендә рәсмиләштерелгән тәртип белән нумерлаштырыла. Әдәбият исемлегеннән тиешле чыганакка күрсәтүче тексттагы сылтамалар квадрат җәяләр рәвешендә рәсмиләштерелә, мәсәлән: [1, 277 б.]. Бит соңында урнаша торган автомат сылтамалар куллану рөхсәт ителми.

Рәсмиләштерү үрнәге:

## СТАТЬЯ ИСЕМЕ

***Фамилиясе, исеме, атасының исеме***
*вазифасы, эш урыны*

Проект эшчәнлеге һәр гомуми белем бирү оешмасы тормышына актив рәвештә үтеп керде. Нәрсә соң ул проект? «Проект» төшенчәсенең берничә билгеләмәсе бар...

«Казанның яңа педагогик сыйныфы»
шәһәр проектында катнашучы
Казан шәһәренең муниципаль
гомуми белем бирү учреждениеләре
өчен конкурс үткәрү тәртибе турында
нигезләмәгә 4 номерлы кушымта
(Форма)

**Материалны, конкурсның электрон җыентыгында бастырып чыгару өчен, www.kazanobr.ru порталында урнаштыруга**
**РӨХСӘТ**

Мин, _____________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________________________________________________________________
(учреждение атамасы)

укучысы/хезмәткәре буларак, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә мәктәп укучыларына һөнәри белем бирүне гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре өчен конкурста катнашу кысаларында минем тарафтан түбәндәге тема буенча язылган проектны бушлай тулы күләмдә https://obr.kzn.ru порталында конкурсның электрон җыентыгында бастырып чыгарырга һәм урнаштырырга (башкалар игътибарына тәкъдим итәргә) рөхсәт итәм:

______________________________________________________________________________________.
(проект атамасы)

Проектның минем тарафтан язылуын һәм башка затларның авторлык хокукларын бозмавын раслыйм.

Минем тарафтан әлеге рөхсәт имзаланган вакыттан алып проектны урнаштыруга рөхсәт бирәм.

20____ елның «______» ___________ ________________ /________________/
(имза) (имзаның аңлатмасы)

«Казанның яңа педагогик сыйныфы»
шәһәр проектында катнашучы
Казан шәһәренең муниципаль
гомуми белем бирү учреждениеләре
өчен конкурс үткәрү тәртибе турында
нигезләмәгә 5 номерлы кушымта
(Форма)

**Муниципаль йөкләмәгә кертелмәгән бер тапкыр үткәрелә торган гомумшәһәр яки башка чараларны оештыруга Казан шәһәренең муниципаль учреждениеләре тарафыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр алуга**
**ГАРИЗА**

Субсидия бирү максаты: ___________________________

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүче | |
| 2 | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры | |
| 3 | Төп дәүләт теркәве номер | |
| 4 | Юридик адресы | |
| 5 | Телефон номеры | |
| 6 | Электрон почта адресы | |
| 7 | Җитәкче | |
| 8 | Субсидия күләме, сумнарда | |
| 9 | Субсидия күчерү өчен реквизитлар | |
| 10 | Субсидия алу мөмкинлеген бирә торган дөрес булмаган мәгълүматлар тапшырган өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык каралган булуы турында әлеге гариза белән хәбәр ителде<br>________________<br>(имза) | |
| 11 | Учреждениенең нигезләмәнең 2.4 пункты белән каралган таләпләргә туры килүен раслыйм | |
| 12 | Субсидия бирү шартлары белән таныштым һәм исемлек буенча кирәкле документларны тапшырам | |

Директор ____________________________________________________________________
(имзасы, вазифасы, фамилиясе һәм инициаллары)

Гариза бирү датасы: 20____елның «___»__________